ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.12.2018 ел Баулы шәһәре №481

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 сентябрендәге 328 номерлы карары белән расланган Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча Иҗтимагый совет хакындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон (2017 елның 29 июлендәге 212-ФЗ номерлы редакция) нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 сентябрендәге 328 номерлы карары белән расланган Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча Иҗтимагый совет хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 04 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган башка затлар керә алмый.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров